КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.04.2023 № 121-П

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында урнашкан «Дума җирлеге (стоянка)» ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен һәм аннан файдалану режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә боерам:

1. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында урнашкан «Дума җирлеге (стоянка)» археологик мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
2. Әлеге боерыкка 2 нче кушымта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында урнашкан «Дума җирлеге (стоянка)» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләрен нигезендә расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
3. Әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында урнашкан «Демка җирлеге (стоянка)» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясен файдалану режимын расларга.
4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.
5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары М.М. Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2023
елның 7 апрелендәге
121-П боерыгына
3 кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында урнашкан «Дума җирлеге (стоянкасы)» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясен файдалану режимы

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү шартларында урманнардан файдалану һәм башка эшләр буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башкару, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен тәэмин итү шартларында археологик кыр эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.

Археологик мирас объекты чикләрендә урнашкан су объектын яисә аның өлешен куллануның аерым режимы ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның әлеге объектка керүен һәм археологик кыр эшләрен уздыруны тәэмин итү шартларында Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.